**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**КУЧУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӨЧЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.10.2024 Түбән Көчек авылы № 13

«2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Түбән Көчек авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Түбән Көчек авыл җирлеге башкарма комитетының 28.07.2023 елның 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законнары, “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе районы Прокуратурасының 05.03.2024 елның 02-08-02-2024/59 номерлы күрсәтмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Түбән Көчек авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Түбән Көчек авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Түбән Көчек авыл җирлеге башкарма комитетының 28.07.2023 елның 11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карарга түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктча өстәргә:

«1.1. Әлеге муниципаль программа индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм "Һөнәри керемгә салым" махсус салым режимын кулланучы физик затларга карата кагыла».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының веб-адрес буенча портал составында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының рәсми сайтында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе

муниципаль районыныңТүбән Көчек авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Ә.Р.Төхвәтуллина